| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ШУГУРОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ШӨГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2023 елның 3 ноябре № 39

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 21 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 21 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктның 3 абзацында «һәм объектлары» сүзләрен «һәм (яисә) объектлары» сүзләренә, «объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләр» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлеше» сүзләренә алмаштырырга, «һәм объектларга» сүзләрен «һәм (яисә) объектларга» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров ур., 17, балалар бакчасы, Киров ур., 23, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин ур., 32, Шөгер авыл мәдәният йорты, Ленин ур., 35, Шөгер 3 участок хастаханәсе, Горький ур., 4 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Советы рәисе Р.Н.Гафиятуллин